| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЗЕЛЕНОДОЛЬСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>СОВЕТЫ |
| **РЕШЕНИЕ**<br>**28.10.2025** | Зеленодольск<br>шәһәре | **КАРАР**<br>**№ 22** |

Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Зеленодольск муниципаль районында бюджет процессы турындагы нигезләмә нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Советы **карар кылды**:

1.Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә Зеленодольск муниципаль районының әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләренең бер өлешен, әлеге карарга 1 нче кушымта буенча, тапшырырга.

2. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитетына 1 нче кушымтада күрсәтелгән Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренең Башкарма комитетлары белән әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында әлеге карарга 2 нче кушымта буенча килешү төзергә.

3. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы составына керүче авыл җирлекләренә бирелә торган финанс чаралары исәбеннән әлеге карарга 3 нче кушымтада каралганча гамәлгә ашырыла.

4. Әлеге карарны интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми (http://pravo.tatarstan.ru) порталында һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) сайтында урнаштырырга.

**Зеленодольск муниципаль районы**
**Башлыгы,**
**Советы рәисе** **М.П. Афанасьев**

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2025 елның
28 октябрендәге 1нче карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Әйшә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

- Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Әйшә авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү

-«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (I этап);

-«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (II этап);

-«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (III этап);

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Октябрь авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү.

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Большие Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

-«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авылы янындагы буаның гидротехник корылмаларын капиталь ремонтлау» проект-смета документациясен эшләү.

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Мулла Иле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

-«Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мулла Иле авылындагы күлне чистарту» проект-смета документациясен эшләү.

**Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы «Бишнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге:**

-Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү.

Зеленодольск муниципаль
районы Советының 2025 елның
28 октябрендәге 22 номерлы
карарына 2 нче кушымта

**Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Җирлекнең Башкарма комитеты арасында вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру/ кабул итү турында**
**КИЛЕШҮ №1**

Зеленодольск шәһәре ___________

Бер яктан Устав нигезендә эш итүче ________исеменнән, Зеленодольск муниципаль районының Башкарма комитеты , алга таба «Район башкарма комитеты» дип аталучы, һәм икенче яктан Устав нигезендә эш итүче Зеленодольск муниципаль районы________ авыл җирлеге Башлыгы исеменнән Зеленодольск муниципаль районы ______авыл җирлеге башкарма комитеты, алга таба «Җирлек башкарма комитеты» дип аталучы, бергә «Яклар» дип аталучы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына һәм Зеленодольск муниципаль районы «______________җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, түбәндәгеләр турында әлеге Килешүне төзеделәр:

## 1. КИЛЕШҮ ПРЕДМЕТЫ

1. Әлеге Килешүнең предметы булып Район башкарма комитеты тарафыннан әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләсе буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру тора:

______________________________________________________________

______________________________________________________________

## 2. ЯКЛАРНЫҢ ХОКУКЛАРЫ ҺӘМ БУРЫЧЛАРЫ

2.1 Район башкарма комитеты түбәндәгеләргә бурычлы:

- 1 бүлектә күрсәтелгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәк булган бюджетара трансфертлар рәвешендә финанс чараларын тапшырырга (алга таба-тапшырылган вәкаләтләр);
- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны бирергә ;
- Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашырганда консультатив һәм методик ярдәм күрсәтергә.

2.2 Район башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

- Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен, шулай ук әлеге килешүнең 3 бүлегендәге бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны контрольдә тотарга. Хокук бозулар ачыкланган очракта, ачыкланган хокук бозуларны бетерү өчен Җирлек башкарма

комитеты тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган язма таләпләрне хәбәр ителгән вакыттан алып билгеле бер срокта җибәрергә;

- Җирлек башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга бәйле кирәкле мәгълүматны, материалларны һәм документларны соратып алырга, шулай ук тапшырылган вәкаләтләрне куллану буенча тәкъдимнәр кертергә;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча Җирлек башкарма комитетына тәкъдимнәр кертергә.

2.3 Авыл җирлеге Башкарма комитеты ттүбәндәгеләргә бурычлы:

- тапшырылган вәкаләтләрне законнар таләпләре нигезендә тиешенчә үтәүне, шул исәптән тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен генә Район Башкарма комитеты тарафыннан бирелгән финанс чараларыннан максатчан файдалануны гамәлгә ашырырга (тәэмин итәргә) ;

- Җирлек башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру буенча ачыкланган хокук бозуларны бетерү турында Район башкарма комитеты тарафыннан тапшырылган язма таләпләрне карарга, бер айдан да соңга калмыйча (әгәр таләптә башка срок күрсәтелмәсә) хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта кичекмәстән Район башкарма комитетына хәбәр итәргә;

- килешүнең гамәлдә булуы туктатылган очракта, файдаланылмаган финанс чараларын кире кайтарырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне тиешенчә үтәү мөмкин булмаган очракта, вәкаләтләрне үтәү мөмкинлеге булмавы билгеле булганнан соң ун көн эчендә бу хакта Район башкарма комитетына язма рәвештә хәбәр итергә.

2.4 Җирлек башкарма комитеты түбәндәгеләргә хокуклы:

- вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен Район башкарма комитеты тарафыннан тапшырыла торган финанс чараларын алырга һәм алардан файдаланырга;

-Район башкарма комитетыннан тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүмат соратып алырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен законнар нигезендә өстәмә рәвештә матди ресурслардан һәм башка финанс чараларыннан файдаланырга;

- тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән, гамәлдәге законнарга каршы килми торган, теләсә нинди башка гамәлләр кылырга.

## 3. БЮДЖЕТАРА ТРАНСФЕРТЛАРНЫҢ ЕЛЛЫК КҮЛӘМЕН БИЛГЕЛӘҮ ТӘРТИБЕ ҺӘМ АНЫ КҮЧЕРҮ СРОКЛАРЫ

3.1. Әлеге Килешүне предметы буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру бюджет законнары нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районының ________ авыл җирлеге бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән гамәлгә ашырыла.

3.2.Яклар тапшырылган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен кирәкле бюджетара трансфертлар күләмен__размерда билгели

3.3.Җирлек башкарма комитеты бюджетара трансфертларны максатчан файдаланмаган очракта, алар Район башкарма комитеты таләбе буенча ун көн эчендә район бюджетына кайтарылырга тиеш.

## 4. ВӘКАЛӘТЛӘРНЕҢ ҮТӘЛЕШЕН КОНТРОЛЬДӘ ТОТУ

4.1. Район башкарма комитеты тапшырылган вәкаләтләрнең үтәлешен тикшерә, Район башкарма комитетының дәлилләнгән соравы буенча

тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында Җирлек башкарма комитетыннан кирәкле мәгълүмат соратып ала.

4.2. Җирлек башкарма комитеты Район башкарма комитетына бу елның 31 декабренә кадәр вәкаләтләрнең үтәлеше, вәкаләтләрне башкару өчен тапшырылган финанс чараларыннан файдалану турында хисап, шулай ук аерым сораулар буенча әлеге Килешү предметына кагылышлы башка мәгълүмат җибәрә.

4.3. Бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануны тикшереп торуны гамәлдәге законнар нигезендә Районның башкарма комитеты, муниципаль финанс контролен гамәлгә ашыручы орган башкара.

## 5. КИЛЕШҮНЕҢ ГАМӘЛДӘ БУЛУ СРОГЫ

5.1. Әлеге Килешү басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

5.2. Якларның берсе дә, әлеге килешүнең гамәлдә булу срогы тәмамланырга бер ай кала, килешүне өзәргә ниятләве турында икенче якка хәбәр итмәгән очракта, ул 1 елга озайтылган дип санала.

## 6. КИЛЕШҮНЕҢ НИГЕЗЛӘРЕ ҺӘМ ГАМӘЛДӘ БУЛУЫН ТУКТАТУ ТӘРТИБЕ

6.1. Килешү, яклар килешүендә башкасы каралган очраклардан тыш, срок узгач гамәлдә булудан туктый.

6.2.Әлеге Килешү вакытыннан алда гамәлдә булудан туктатылырга мөмкин:

- Яклар килешүе буенча.

-түбәндәге очракларда берьяклы тәртиптә:

- Россия Федерациясенең һәм (яки) Татарстан Республикасының гамәлдәге законнарын үзгәртү нәтиҗәсендә Район Башкарма комитеты тарафыннан әлеге Килешү нигезендә тапшырыла торган вәкаләтләрне башкару мөмкин булмаса, йә килеп туган шартларда әлеге вәкаләтләр Җирлек Башкарма комитеты тарафыннан аеруча нәтиҗәле гамәлгә ашырылырга мөмкин булганда.

- Якларның берсе әлеге Килешү нигезендә үз йөкләмәләрен үтәмәве яисә тиешенчә үтәмәве.

6.3. Әлеге Килешүне өзү турында хәбәрнамә язма рәвештә җибәрелә. Әлеге Килешү күрсәтелгән хәбәрнамәне җибәргәннән соң 30 көн узгач өзелгән дип санала

6.4. Әлеге Килешүнең гамәлдә булуы вакытыннан алда туктатылган очракта, Җирлек башкарма комитеты Район башкарма комитетына вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен тапшырылган файдаланылмаган финанс чараларын кайтара.

## 7. ЯКЛАРНЫҢ ҖАВАПЛЫЛЫГЫ

7.1. Яклар әлеге Килешүдә каралган бурычларны үтәмәгән (тиешенчә үтәмәгән) өчен Россия Федерациясе законнары һәм әлеге Килешү нигезендә җавап тоталар.

7.2. Әлеге Килешү буенча йөкләмәләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү законнарда каралган җаваплылык башлануга нигез булырга мөмкин.

## 8. КИЛЕШҮНЕ ҮТӘМӘГӘН ӨЧЕН ФИНАНС САНКЦИЯЛӘРЕ

8.1. Якларның берсе әлеге килешү буенча үз йөкләмәләрен үтәмәгән өчен гаепле як икенче якка әлеге килешүгә кушымтада каралган финанс чаралары күләменнән 0,1% күләмендә штраф түли.

8.2. Штраф түләү Якларны әлеге Килешү буенча бурычларын алга таба үтәүдән азат итми.

## 9. БӘХӘСЛӘРНЕ ХӘЛ ИТҮ ТӘРТИБЕ

9.1. Әлеге Килешүне үтәүгә бәйле бәхәсләр Яклар тарафыннан сөйләшүләр уздыру һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл ителә.

9.2. Бәхәсне сөйләшүләр алып бару һәм башка килештерү процедураларыннан файдалану юлы белән хәл итү мөмкин булмаган очракта, ул суд тәртибендә законнар нигезендә каралырга тиеш

## 10. ЙОМГАКЛАУ НИГЕЗЛӘМӘЛӘРЕ

10.1. Әлеге Килешүгә барлык үзгәрешләр һәм өстәмәләр Якларның үзара ризалыгы белән кертелә һәм язма рәвештә өстәмә килешү белән рәсмиләштерелә. Өстәмә килешүләр әлеге килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

10.2. Әлеге килешү белән җайга салынмаган мәсьәләләр буенча яклар гамәлдәге законнарга таянып эш итәләр.

10.3. Чираттагы финанс елының 1 гыйнварына файдаланылмаган башка бюджетара трансфертлар РФ БК 242 ст нигезендә Зеленодольск муниципаль районы бюджетына кайтарылырга тиеш.

10.4. Әлеге тигез юридик көчкә ия булган Килешү 2 (ике) нөсхәдә, һәр Як өчен бер нөсхәдә төзелгән.

10.5.Әлеге килешүгә кушымта итеп бирелә:

«Бюджетара трансфертлар күләме» кушымтасы.

## 11. ЯКЛАРНЫҢ ИМЗАЛАРЫ

| | |
|---|---|
| Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль<br>районының Башкарма комитеты<br>җитәкчесе | Татарстан Республикасы<br>Зеленодольск муниципаль<br>районының ____________ авыл<br>җирлеге Башлыгы |
| ___________/______________/ | ___________/ ______________/ |
| «____» _________20______ел | «____» ____________20__ел |

2025 елның 28 октябрендәге 22 номерлы Зеленодольск муниципаль районы Советы карарына 3 нче кушымта

| Муниципаль берәмлек | Табигатьне саклау чарасы исеме | Агымдагы бәяләрдә хакы (мең сум) |
|---|---|---|
| Әйшә авыл җирлеге | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Әйшә авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү | 218 |
| | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (I этап); | 590 |
| | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (II этап); | 590 |
| | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Ильинский авылы янында Сумка елгасы үзәнен чистарту» проект-смета документациясен эшләү (III этап); | 590 |
| Октябрь авыл җирлеге | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Октябрь авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү | 350 |
| Большие Ключи авыл җирлеге | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Большие Ключи авылы янындагы буаның гидротехник корылмаларын капиталь ремонтлау» проект-смета документациясен эшләү. | 140 |
| Мулла Иле авыл җирлеге | «Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Мулла Иле авылындагы күлне чистарту» проект-смета документациясен эшләү. | 590 |
| Бишнә авыл җирлеге | Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Бишнә авыл җирлегендә калдыкларны рөхсәтсез урнаштыру урыннарын бетерү. | 190,20204 |